Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Яңа Никольский авыл Советы

КАРАРЫ

16 июль 2024 ел № 95

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Никольский авыл Советының 2013 елның 25 ноябрендәге 112 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Никольский авыл җирлеге территориясендә җир салымы турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, Әлмәт муниципаль районы Яңа Никольский авыл җирлеге Уставының 28 статьясы нигезендә

Яңа Никольский авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Никольский авыл Советының 2013 елның 25 ноябрендәге 112 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Никольский авыл җирлеге территориясендә җир салымы турында» карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Никольский авыл Советының 2014 елның 19 ноябрендәге 155 номерлы, 2015 елның 5 маендагы 178 номерлы, 2020 елның 12 маендагы 129 номерлы, 2020 елның 18 ноябрендәге 5 номерлы, 2023 елның 15 декабрендәге 84 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 5 пунктка түбәндәге эчтәлекле алтынчы абзац өстәргә:

«гомуми файдаланудагы җир кишәрлекләренә (территорияләргә) карата казна, бюджет һәм автоном учреждениеләр («урам-юл челтәре», «территорияне төзекләндерү» куллану төрләрен кертеп»).»;

1.2. 5 пунктның алтынчы абзацын җиденче абзац дип санарга.

2. Әлеге карарны “Альметьевский вестник” газетасында бастырып чыгарырга, Әлмәт районы, Новоникольск авылы, Үзәк урамы, 100 йорт, Салкын Алан авылы, Луговая урамы, 60 йорт, Иштирәк урамы, Чишмә урамы, 3 йорт, Хазовка, Болтай поселоклары, Завод, Каменка, Кече Шуган, Поташная Поляна, Сосновка территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында игълан итәргә, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайты «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2024 елның 1 гыйнвареннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Яңа Никольский авыл җирлеге башлыгы Р. Г. Фазлыев